**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы**
**«Иске Кади авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлеге**
**гражданнары җыены карары**

**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы Иске Кади авыл җирлегенең**
**Иске Кади торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре**
**турында**

16 октябрь 2025 ел № 3

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы 45,69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2025 елның 16 октябрендә киләсе мәсьәлә буенча үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: «2026 елда Чирмешән муниципаль районы Иске Кади авыл җирлегенең Иске Кади торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә 1 төркем инвалидлардан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, Луганск халык республикасы һәм Донецк халык республикасы махсус операциясендә булган затлардан, 90 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге кешеләрдән тыш һәм алынган чараларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә җибәрү белән килешәсезме:

- **торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү** (юл кырыйларын чабу, юлларны грейдерлау, кышкы вакытта урамнарны кардан чистарту) Иске Кади торак пунктында трактор өчен ягулык-майлау материаллары һәм запас частьләр сатып алу, тракторчыга исәпләнгән хезмәт хакы түләү, Иске Кади торак пунктында ике дәүләт телендә (рус һәм татар телләрендә) йорт номерлары һәм урам исемнәре язылган элмә такталар әзерләү һәм урнаштыру, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу, хезмәт күрсәтүләр өчен түләү;

- **урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны**

**ремонтлау** (урам яктырткычларын монтажлау, ремонтлау, алмаштыру, Иске Кади торак пунктында урамнарны яктырту өчен кулланыла торган электр энергиясе чыгымнарын түләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу, хезмәтләр өчен түләү.

**- урамнарны яктырту җайланмасы** (Иске Кади авылының Тукай урамында урам яктырткычлары кую, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу, хезмәт күрсәтүләргә түләү)

**- янгынга каршы резервуарлар (янгын сулыклары), янгын пирслары төзү, ремонтлау** (Иске Кади авыл җирлеге территориясендә язгы ташудан соң сулыкларга янгынга каршы керү юлларын торгызу);

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенының 363 катнашучысы кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 201 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында 201 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен беркем дә тавыш бирмәде.

Бәян ителгәннәр нигезендә халык җыены карар кылды:

1.Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Кади авыл җирлегенең Иске Кади торак пунктында халык җыены **булып узган, халык җыены нәтиҗәләре - чын дип танырга.**

2. Киләсе мәсьәлә буенча: «2026 елда Чирмешән муниципаль районы Иске Кади авыл җирлегенең Иске Кади торак пункты территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә I төркем инвалидлардан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, Луганск халык республикасы һәм Донецк халык республикасы махсус операциясендә булган затлардан, 90 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге кешеләрдән тыш, алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

**- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү** (юл кырыйларын чабу, юлларны грейдерлау, кышкы вакытта урамнарны кардан чистарту) Иске Кади торак пунктында трактор өчен ягулык-майлау материаллары һәм запас частьләр сатып алу, тракторчыга исәпләнгән хезмәт хакы түләү, Иске Кади торак пунктында ике дәүләт телендә (рус һәм татар

телләрендә) йорт номерлары һәм урам исемнәре язылган элмә такталар әзерләү һәм урнаштыру, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу, хезмәт күрсәтүләр өчен түләү;

**- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау** (урам яктырткычларын монтажлау, ремонтлау, алмаштыру, Иске Кади торак пунктында урамнарны яктырту өчен кулланыла торган электр энергиясе чыгымнарын түләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу, хезмәтләр өчен түләү.

**- урамнарны яктырту җайланмасы** (Иске Кади авылының Тукай урамында урам яктырткычлары кую, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу, хезмәт күрсәтүләргә түләү)

**- янгынга каршы резервуарлар (янгын сулыклары), янгын пирслары төзү, ремонтлау** (Иске Кади авыл җирлеге территориясендә язгы ташудан соң сулыкларга янгынга каршы керү юлларын торгызу) **кабул ителгән дип танырга.**

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен мәгълүмати стендларда урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә: Иске Кади авылы, Совет ур., 6нчы йорт, Чирмешән муниципаль районының рәсми интернет-сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче
ТР Чирмешән муниципаль районы
Иске Кади авыл җирлеге башлыгы Н.В.Мөктәсимов